КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 3 март г.Казань № 155

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2025 ел, 25 сентябрь, 752 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2025 ел, 25 сентябрь, 752 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче абзацта «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең» сүзләрен «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, «Гаилә күпфункцияле үзәге» бүлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең» сүзләрен «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, «Гаилә күпфункцияле үзәге» бүлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының стационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-эш хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләрнең коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтүне кертеп) норматив чыгымнарда:

I бүлекнең 2 пунктындагы 2 графасында «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлар» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекнең 2 пунктындагы 2 графасында «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортлар» сүзләрен «Социаль хезмәт күрсәтү йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль берәмлекләр (шәһәр округлары) территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре составына керә торган гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләренең дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

исемендә «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең» сүзләрен «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, «Гаилә күпфункцияле үзәге» бүлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктның 2 графасында «Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләре, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләре» сүзләрен «Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләре, «Гаилә күпфункцияле үзәге» бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнар составында башка чыгымнарга төзәтү коэффициентларының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2. | Социаль хезмәт күрсәтү йортлары | |
| 2.1. | «Алабуга социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,00 |
| 2.2. | «Зеленодольск социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,22 |
| 2.3. | «Чистай социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,20 |
| 2.4. | «Казан социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,36 |
| 2.5. | «Яңа Чүриле социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,31 |
| 2.6. | «Кама Аланы социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ | 1,04»; |

әлеге карар белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль берәмлекләр (шәһәр округлары) территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре составына керә торган гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләренең дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә норматив чыгымнар составында башка чыгымнарга төзәтү коэффициентлары исемендә «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәкләренең, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең» сүзләрен «гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләренең, «Гаилә күпфункцияле үзәге» бүлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль берәмлекләр (шәһәр округлары) территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтүнең

стационар рәвеше белән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында ятак-көннәр һәм ятак-урыннар санында:

«Арча муниципаль районы» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Яңа Чүриле интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Яңа Чүриле социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Алабуга муниципаль районы» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Алабуга интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Алабуга социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Зеленодольск муниципаль районы» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Зеленодольск интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Зеленодольск социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Түбән Кама муниципаль районы» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Кама Аланы интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Кама Аланы социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Чистай муниципаль районы» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Чистай интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Чистай социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

«Казан шәһәре» юлының 2 нче графасында «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Казан интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Казан социаль хезмәт күрсәтү йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин